# Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Күл Черкене авыл җирлеге составына керүче Лашчы тимер юл разъезды торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында карар

17.11.2023 № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә «Күл Черкене авыл җирлегенең Лашчы тимер юл разъезды поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2023 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә – Лашчы тимер юл разъезды торак пунктында зиратларны төзекләндерүгә (коймаларны яңартуга, чүп үләне белән көрәшкә), урамнарны яктырту яктырткычлары сатып алуга, мәчет янындагы территориядә өскорма төзүгә, асфальт юл өслеген чокырдан ремонтлауга тотуга Сез ризамы?» дигән сорау буенча 2023 елның 17 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау 238 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны- 143 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашкан 143 кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Буа муниципаль районы Күл Черкене авыл җирлеге составына керүче Лашчы тимер юл разъезды поселогында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләре гамәлдә, дип танырга.

2 «Күл Черкене авыл җирлегенең Лашчы тимер юл разъезды поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2023 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә – Лашчы тимер юл разъезды торак пунктында зиратларны төзекләндерүгә (коймаларны яңартуга, чүп үләне белән көрәшкә), урамнарны яктырту яктырткычлары сатып алуга, мәчет янындагы территориядә өскорма төзүгә, асфальт юл өслеген чокырдан ремонтлауга тотуга Сез ризамы?» дигән сорау буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Буа муниципаль районының рәсми сайтында һәм Лашчы тимер юл разъезды поселогында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Күл Черкене авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: __________ М.К. Истиев

Күл Черкене авыл җирлеге
башлыгы _________________ М.К. Истиев